**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлегенең Тимәш торак пунктында гражданнар җыены карары**

2024 елның 23 ноябре № 7

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлегенең Тимәш торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлегенең Тимәш торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2025 елда Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлегенең Тимәш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 (Өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, 1, 2 төркем инвалидлардан; хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан; мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан; контракт хезмәте хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан; көндезге бүлектә белем алучы студентлардан; ялгыз пенсионерлардан тыш,

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тимәш торак пунктында Киров, Урман, Яшьләр, Нефтьүткәргечләр,Октябрь, Родничная, Төньяк, Тукай, Мәктәп урамнары буйлап юлларны кардан чистарту; Тимәш авылында Утыз Имәни урамыннан Яшьләр урамына керү юлында асфальт түшәмә белән чокырларны ремонтлау );

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (Тимәш торак пунктында җәйге вакытта кулдан үлән чабу (килешү буенча түләү).

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Тимәш авылы, Утыз Имәни урамы, 71А йорты, җирле үзидарә бинасы, Киров урамы, авыл мәдәният йортының 2-бинасы, Нефтепроводчиклар урамы, Ромашкино РНУ БПО утырышларының 20-залы, Киров ур., 1А-йорты «Ласточка» балалар бакчасы бинасы, Урман ур., 20, Урман ур., 33 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районының
Тимәш авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Сөләйманова